**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О физической культуре и спорте» и Закон Республики Татарстан «О местном самоуправлении в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
17 октября 2015 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 8 октября 2008 года № 99-ЗРТ «О физической культуре и спорте» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2008, № 10 (I часть); 2010, № 6 (I часть); 2011, № 5; 2012, № 7 (I часть), № 12 (II часть); 2013, № 6 (II часть); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II часть); 2015, № 3, № 7 (I часть) следующие изменения:

1) в статье 6:

а) в части 1:

дополнить пунктом $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$) участие в подготовке программ развития видов спорта в части включения в них мероприятий по развитию детско-юношеского спорта, школьного спорта, массового спорта, спорта инвалидов и лиц с ограниченными возможностями здоровья в Республике Татарстан в соответствии с Федеральным законом;»;

дополнить пунктами $4^1$ – $4^4$ следующего содержания:

«$4^1$) развитие детско-юношеского спорта в целях создания условий для подготовки спортивных сборных команд Республики Татарстан и спортивного резерва для спортивных сборных команд Республики Татарстан;

$4^2$) содействие развитию массового спорта, спорта высших достижений;

$4^3$) содействие развитию профессионального спорта путем предоставления государственной поддержки физкультурно-спортивным организациям, основным видом деятельности которых является развитие профессионального спорта;

$4^4$) содействие в осуществлении мероприятий по подготовке спортивных сборных команд Республики Татарстан к всероссийским, межрегиональным и региональным официальным спортивным мероприятиям и по участию в них, в том числе путем предоставления государственной поддержки республиканским спортивным федерациям в соответствии с Федеральным законом и нормативными правовыми актами Республики Татарстан;»;

пункт 6 изложить в следующей редакции:

«6) присвоение спортивных разрядов и квалификационных категорий спортивных судей в соответствии со статьей 22 Федерального закона;»;

дополнить пунктами $9^2$ – $9^5$ следующего содержания:

«$9^2$) участие в обеспечении подготовки спортивного резерва для спортивных сборных команд Российской Федерации;

$9^3$) методическое обеспечение организаций, осуществляющих спортивную подготовку;

$9^4$) координация деятельности физкультурно-спортивных организаций по подготовке спортивного резерва для спортивных сборных команд Республики Татарстан и участию спортивных сборных команд Республики Татарстан в межрегиональных и во всероссийских спортивных соревнованиях;

$9^5$) создание условий для осуществления инновационной и экспериментальной деятельности в области физической культуры и спорта в Республике Татарстан и внедрения достигнутых результатов в практику;»;

б) в части 2:

пункт 1 признать утратившим силу;

пункт 4 изложить в следующей редакции:

«4) оказывать содействие развитию школьного спорта, студенческого спорта;»;

2) часть $1^1$ статьи 12 после слова «волонтерам» дополнить словами «, контролерам-распорядителям»;

3) часть 4 статьи 14 изложить в следующей редакции:

«4. Спортивные разряды «кандидат в мастера спорта», «первый спортивный разряд» и квалификационная категория спортивного судьи «спортивный судья первой категории» присваиваются специально уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в области физической культуры и спорта в порядке, установленном соответственно Положением о Единой всероссийской спортивной классификации и Положением о спортивных судьях. Спортивные разряды «второй спортивный разряд», «третий спортивный разряд», квалификационные категории спортивных судей «спортивный судья второй категории», «спортивный судья третьей категории» присваиваются органами местного самоуправления муниципальных районов и городских округов в порядке, установленном соответственно Положением о Единой всероссийской

спортивной классификации и Положением о спортивных судьях. Спортивные разряды «первый юношеский спортивный разряд», «второй юношеский спортивный разряд», «третий юношеский спортивный разряд», квалификационная категория спортивных судей «юный спортивный судья» присваиваются физкультурно-спортивными организациями в порядке, установленном соответственно Положением о Единой всероссийской спортивной классификации и Положением о спортивных судьях.»;

4) пункт 6 части 1 статьи 28 дополнить словами «, в том числе предусмотренных Федеральным законом».

**Статья 2**

Внести в Закон Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 7 (II часть); 2005, № 2, № 4 (I часть), № 6 (II часть), № 11; 2006, № 4, № 7 (I часть); 2007, № 7 (I часть), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (II часть); 2011, № 3, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2013, № 3, № 7, № 12 (I часть); 2014, № 5, № 11 (VI часть); 2015, № 7 (I часть) следующие изменения:

1) в статье 15:

а) пункт 14 части 1 изложить в следующей редакции:

«14) обеспечение условий для развития на территории поселения физической культуры, школьного спорта и массового спорта, организация проведения официальных физкультурно-оздоровительных и спортивных мероприятий поселения;»;

б) пункт 7 части 3 изложить в следующей редакции:

«7) обеспечение условий для развития на территории поселения физической культуры, школьного спорта и массового спорта, организация проведения официальных физкультурно-оздоровительных и спортивных мероприятий поселения;»;

2) пункт 26 части 1 статьи 16 изложить в следующей редакции:

«26) обеспечение условий для развития на территории муниципального района физической культуры, школьного спорта и массового спорта, организация проведения официальных физкультурно-оздоровительных и спортивных мероприятий муниципального района;»;

3) пункт 19 части 1 статьи 17 изложить в следующей редакции:

«19) обеспечение условий для развития на территории городского округа физической культуры, школьного спорта и массового спорта, организация проведения официальных физкультурно-оздоровительных и спортивных мероприятий городского округа;».

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань,Кремль
3 ноября 2015 года
№ 89-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Физик культура һәм спорт турында” Татарстан Республикасы Законына һәм “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 17 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Физик культура һәм спорт турында” 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:
а) 1 өлештә:
түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:
“$1^1$) спорт төрләрен үстерү программаларын әзерләүдә бу программаларга Татарстан Республикасында балалар-яшүсмерләр спортын, мәктәп спортын, массакүләм спортны, инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар спортын үстерү чараларын кертү өлешендә Федераль закон нигезендә катнашу;”;
түбәндәге эчтәлекле $4^1$ – $4^4$ пунктлар өстәргә:
“$4^1$) Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларын һәм Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларына спорт резервын әзерләү өчен шартлар тудыру максатларында балалар-яшүсмерләр спортын үстерү;
$4^2$) массакүләм спортны, югары казанышлар спортын үстерүгә булышу;
$4^3$) эшчәнлекләренең төп төре һөнәри спортны үстерү булган физкультура-спорт оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү юлы белән һөнәри спортны үстерүгә булышу;
$4^4$) Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларын бөтенроссия, төбәкара һәм төбәк рәсми спорт чараларына әзерләү һәм аларда катнашу чараларын гамәлгә ашыруга булышу, шул исәптән республика спорт федерацияләренә Федераль закон һәм Татарстан Республикасы хокукый актлары нигезендә дәүләт ярдәме күрсәтү юлы белән дә;”;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6) Федераль законның 22 статьясы нигезендә спорт разрядлары һәм спорт судьяларының квалификация категорияләрен бирү;”;

түбәндәге эчтәлекле $9^2 – 9^5$ пунктлар өстәргә:

“$9^2$) Россия Федерациясе спорт җыелма командалары өчен спорт резервын әзерләүдә катнашу;

$9^3$) спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны методик яктан тәэмин итү;

$9^4$) физкультура-спорт оешмалары эшчәнлеген Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары өчен спорт резервын әзерләү һәм Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларының төбәкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында катнашуы буенча координацияләү;

$9^5$) Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт өлкәсендә инновацион һәм эксперименталь эшчәнлекне башкару һәм ирешелгән нәтиҗәләрне гамәлгә кертү өчен шартлар тудыру;”;

б) 2 өлештә:

1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4) мәктәп спорты, студентлар спорты үсешенә булышу;”;

2) 12 статьяның $1^1$ өлешендә “Волонтерларга” сүзеннән соң “, контролер-эш йөртүчеләргә” сүзләрен өстәргә;

3) 14 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. “Спорт мастерына кандидат”, “беренче спорт разряды” спорт разрядлары һәм “беренче категорияле спорт судьясы” спорт судьясының квалификация категориясе тиешенчә Бердәм бөтенроссия спорт классификациясе турында нигезләмәдә һәм Спорт судьялары турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органы тарафыннан биреләләр. “Икенче спорт разряды”, “өченче спорт разряды” спорт разрядлары, “икенче категорияле спорт судьясы”, “өченче категорияле спорт судьясы” спорт судьяларының квалификация категорияләре тиешенчә Бердәм бөтенроссия спорт классификациясе турында нигезләмәдә һәм Спорт судьялары турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан биреләләр. “Яшүсмерләрнең беренче спорт разряды”, “яшүсмерләрнең икенче спорт разряды”, “яшүсмерләрнең өченче спорт разряды” спорт разрядлары, “яшь спорт судьясы” спорт судьяларының квалификация категориясе тиешенчә Бердәм бөтенроссия спорт классификациясе турында нигезләмәдә һәм Спорт судьялары турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә физкультура-спорт оешмалары тарафыннан биреләләр.”;

4) 28 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктка “бүтән” сүзеннән соң “, шул исәптән Федераль законда каралган” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяда:
а) 1 өлешнең 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“14) җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;”;
б) 3 өлешнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“7) җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;”;

2) 16 статьяның 1 өлешендәге 26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“26) муниципаль район территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, муниципаль районның рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;”;

3) 17 статьяның 1 өлешендәге 19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“19) шәһәр округы территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәр округының рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;”.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 3 ноябре
№ 89-ТРЗ